Саранскида Идел буе федераль округынын ин яхшы журналистлары жыелды. Алар барысы да «СМИротворец» XVI Ботенроссия массакvлэм мэгълvмат чаралары конкурсынын округ этабында катнаштылар. Конкурс кvпмиллэтле Россия халыкларынын тормышын, мэдэниятен һэм гореф-гадэтлэрен яктыртучы журналистларнын һонэри эшчэнлеген һэм ижатын, этномэдэни vсеш мэсьэлэлэрен, Россия миллэтенен бердэмлеген ныгытуны бэяли.

Эксперт советы тарафыннан Идел буе федераль округынын 162 массакvлэм мэгълvмат чарасыннан 2 менгэ якын журналист эше каралды, э округ этабында жинvгэ 11 субъекттан 33 массакvлэм мэгълvмат чарасы дэгъва кылды. Бу чара кысаларында торле темаларны яктырткан чаралар берничэ кон (5 - 7.10.2024.) дэвамында vтте. Шул исэртэн тvгэрэк остэллэр, мастер-класслар, экскурсиялэр, тэжрибэ уртаклашулар кызыклы һэм файдалы булды.

«СМИротворец» XVI Ботенроссия массакvлэм мэгълvмат чаралары конкурсынын округ этабына йомгак ясарга һэм жинvчелэрне, лауреатларны котларга 7 октябрьдэ Мордовия Главасы Артём Здунов килде. Респуб-лика житэкчесе билгелэп vткэнчэ, «...Миллэтара тынычлыкны һэм конфессияара татулыкны ныгыту – дэvлэт сэясэтенен стратегик бурычлары, аларнын эһэмиятен Президентыбыз кvп тапкырлар ассызыклады. Махсус

хәрби операция шартларында бу юнәлеш аеруча мөһим. Милләтара монәсәбәтләр - Россия бердәмлегенен таянычы», - диде Артём Здунов.
Россия тәҗрибәсе уникаль - илдә 277 телдә сойләшvче 193 милләт вәкиле яши. Мордовиягә килгәндә, биредә 90нан артык милләт вәкилләре яши, доньянын 60 иленнән студентлар укый. Бездә 500 дән артык иҗтимагый милли һәм мәдәни, дини оешмалар – бу безнен байлыгыбыз. Безбик моһим эш белән шогыльләнәбез. Президентыбызга һәм ил житәкчелегенә бездә Президент грантлары Фонды булган һәм без ярдәм ала алганнары очен рәхмәт белдерәсем килә, - диде Мордовия Главасы. - Ике ел рәттән Президент мәдәни инициативалар фонды ярдәме белән Саранск «Без бергә» Ботенроссия милли мәдәниятләр фестивален кабул итә. Быел республиканын милли сәясәте олкәсендә топ чара мордва халкынын тобәкара иҗтимагый оешмасынын сигезенче съезды булачак - ул ике коннән старт алачак».

Этникара журналистиканы vстерvгә, Россия халыкларынын бердәмлеген ныгытуга керткән зур шәхси олеше очен Мордовия Главасы Артём Здунов конкурснын идея рухын кvтәрvче - Этникара журналистика гильдиясе президенты, милләтара монәсәбәтләр буенча РФ Президенты каршындагы

Совет әгъзасы, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы Маргарита Лянгага Рәхмәт хаты тапшырды.
Артём Здунов жинvчеләрне бvләкләvдә катнашты. «Россия халыкларынын гаилә традицияләре» номинациясендә «Известия Мордовии» газетасы жинv яулады, «Интернет» номинациясендә - «Удмуртия» мәгълvмат агентлыгы, «Телевидение»

номинациясендә - Пермь краенын Березники шәһәреннән «Свое ТВ» телеканалы, «Матбугат» номинациясендә ин яхшы «Пензенская правда» олкә газетасы. Округ этабында беренче урыннарны алган журналистлар vз тобәкләрен федераль конкурста тәкъдим итәчәк.